ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05 12 2022 г. № 869

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетында күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым Административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 685 номерлы карары белән расланган яңа редакциядә Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары нигезендә физик һәм юридик затларны мәгълүмат белән тәэмин итү буенча, архив белешмәләрен, архив өземтәләрен һәм архив документлары күчермәләрен тәкъдим итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 686 номерлы карары белән расланган спорт разрядын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 июлендәге 688 номерлы карары белән расланган регуляр ташу маршруты һәм регуляр ташу маршруты картасы буенча ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык рәсмиләштерү буенча, регуляр ташу маршруты һәм регуляр ташу маршруты картасы буенча ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкны яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Алдан башкару (проактив) режимында муниципаль хезмәт күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәтләрне алдан башкару (актив) режимында күрсәтү гариза бирүче тарафыннан аңа әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан башкару (проактив) режимында күрсәтү турында алдан сорату бирү шартларында һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан 210-ФЗ номерлы Федераль

законның 7.3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә чаралар гамәлгә ашырылганнан соң, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/)» техник мөмкинлекне гамәлгә ашыру аша күрсәтелә;

2.10 пунктны «оешмалар тарафыннан бирелә торган» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан» сүзләре белән тулыландырырга;

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.0 пунктын өстәргә:

«3.0. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган, шул исәптән алар алу өчен мөрәҗәгать иткән уртак билгеләр белән берләшкән муниципаль хезмәт нәтиҗәләренә карата муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.14 пункты һәм әлеге бүлек белән билгеләнгән.»;

3.1.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) техник хатаны төзәтү.»;

3.3.2.1 пунктның 10 абзацын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү гариза бирүче тарафыннан сорату электрон формасының һәр кырын тутыру процессында бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал соратуның электрон формасы кыры дөрес тутырылмавын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры соратуның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ * РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МКУ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874